КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 10 октябрь г.Казань № 1284

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 26 февраль, 110 нчы; 2018 ел, 7 май, 327 нче; 2018 ел, 30 июль, 614 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1288 нче; 2019 ел, 23 апрель, 329 нчы; 2019 ел, 18 декабрь, 1165 нче; 2020 ел, 11 февраль, 87 нче; 2020 ел, 15 май, 392 нче; 2020 ел, 8 август, 666 нчы; 2021 ел, 17 июнь, 467 нче; 2021 ел, 11 август, 700 нче; 2021 ел, 6 сентябрь, 817 нче; 2021 ел, 27 ноябрь, 1140 нчы; 2021 ел, 9 декабрь, 1209 нчы; 2022 ел, 7 март, 202 нче; 2022 ел, 17 март, 244 нче; 2022 ел, 29 апрель, 402 нче; 2022 ел, 22 сентябрь, 1029 нчы; 2022 ел, 11 ноябрь, 1196 нчы, 2023 ел, 6 март, 214 нче, 2023 ел, 21 март, 306 нчы, 2023 ел, 17 июль, 851 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «оештыру һәм аларныж эшләве» сүзләрен «саклау һәм алардан файдалану» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктта:

бишенче абзацта «оештыру һәм аларныж эшләве» сүзләрен «саклау һәм алардан файдалану» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә федераль дәүләт аучылык контроле (күзәтчелеге) (федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш) (01.06.18).»;

4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Закон нигезендә Дәүләт комитетына махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә һәм флораны куллану һәм яңадан җитештерү өлкәсендә түбәндәге вәкаләтләр йөкләнә:»;

4.2.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2.1. Түбәндәге хокукый актлар проектларын әзерли һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга кертә:

төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территорияләрен булдыру, төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территорияләрен махсус саклау режимының бурычлары һәм үзенчәлекләре турында;

үсемлекләр дөньясы объектларын саклауга бәйле мөнәсәбәтләр өлкәсендә;».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2023 ел, 26 июнь, 752 нче карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт идарәсе функцияләре кодификаторы, «01.06.07» юлының 8 графасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә идарә итү, Татарстан Республикасы Кызыл китабын алып бару».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин